СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

27.10.2022 | с. Шеланга | 22-114

Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Кызыл Байрак торак пункты территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Шилангы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Шилангы торак пунктының бер өлешендә яшәүчеләр төркеме инициативасын карап чыгып,

Югары Ослан муниципаль районының
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2022 елның 8 октябрендә Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Кызыл Байрак торак пункты территориясендә гажданнардан үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Шеланга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 20 000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сосновая, Приволжская, Лесная урамнары юлларын реконструкцияләү

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Кызыл-Байрак п., Сосновая ур., 1 нче йорт янында 11.00 сәгатьтә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шиланга авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров